**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 6 июнендәге 2331 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 4 мартындагы 734 номерлы «Казан шәһәре Яңа Савин районының Маршал Чуйков урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 4 мартындагы 734 номерлы «Казан шәһәре Яңа Савин районының Маршал Чуйков урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы нигезендә һәм техник хата җибәрелү сәбәпле **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 4 мартындагы 734 номерлы «Казан шәһәре Яңа Савин районының Маршал Чуйков урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.3 пунктчасында «ТП-2510» сүзләрен «ТП-1623» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 6.1 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**